# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**№ 2** **16. 11.2019 ел**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль
районы Чубар-Абдул авыл җирлегенэ керүче
Буралы авылында 2020 елда үзара салым
жыюны кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлегендә халык җыены карар бирә:

1. 2020 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлеге Буралы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, 300 сум күләмендә үзара салым кертү.
2. Бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү

- юлларга щебенка җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү) Буралы авылында Октябрьская урамы, Школьная урамы
- Буралы авылында («Яңа ел», «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне») бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү;
- Буралы авылында урам исемнәре язылган табличкалар ясау;
- урам утларын, яктырткычларны, махсус җиһазларны сатып алу, энергия саклаучы лампаларны урнаштыру, килешү буенча эш өчен түләү

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Чубар-Абдул авыл җирлеге башлыгы: Н. Ә. Фәтхетдинов